**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Олы Мәңгәр авыл җирлеге Олы Мәңгәр торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"16" ноябрь 2023 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлегенең Олы Мәңгәр торак пунктында халык җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Олы Мәңгәр авылы территориясендә 2024 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлегенең Олы Мәңгәр авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидларыннан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларыннан, РФ Оборона министрлыгы белән контракт төзегән хәрби хезмәткәрләрдән һәм, РФ Оборона министрлыгы белән контракт төзегән хәрби хезмәткәрләренен гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Арча - Әтнә юлы янында урнашкан "Кодрале" чишмәсе һәм "Рөстәм коесын" чистарту, төзекләндерү һәм су алуны җайлаштыру (материаллар сатып алу һәм хезмәт күрсәтүгә түләү);

2) Урам яктыртуына хезмәт күрсәтү (яктырткычларны, ут чыбыкларын ремонтлау һәм лампаларны алмаштыру өчен материаллар сатып алу);

3) Олы Мәнгәр авылы зираты территориясен төзекләндерү һәм чистарту (агачларны кисү һәм чистарту).

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлегенең Олы Мәңгәр авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Олы Мәңгәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Олы Мәңгәр авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Мәңгәр авыл җирлеге башлыгы Филатова Ф.Ф.